ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.07.2025 МӨСЛИМ № 383

**Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаны раслау турында» 2023 елның 22 декабрендәге 609 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 23.06.2016 ел, №182 Федераль закон нигезендә, хокук бозуларны профилактикалауның күп дәрәҗәле системасын булдыру, хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген ныгыту, күрсәтелгән эшчәнлеккә дәүләт органнарын, иҗтимагый формированиеләрне һәм халыкны җәлеп итү, җинаятьләр кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны локальләштерү, шулай ук «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2017 елның 11 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаны раслау турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 22 декабрендәге 609 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2024-2028 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программага «Мәгълүмати-коммуникация технологияләреннән файдаланып кылына торган җинаятьләрне профилактикалау» дигән 7 бурычны кушымта нигезендә өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**